**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 сентябрь № 658

г. Казань

Архив документларын саклау берәмлеген карап тотуга чыгымнар нормативын раслау турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 ел, 24 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Дәүләт милкенә караган архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм файдалануга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган субвенция күләмен исәпләү өчен архив документларын саклауның 1 берәмлеген карап тотуга чыгымнар нормативын 2015 – 2017 елларга 10,2 сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Архив документларын саклау берәмлеген карап тотуның уртача кыйммәтенә исәпләгәндә дәүләт вәкаләтләрен үтәү чыгымнарының исәп-хисап нормативын раслау турында» 2014 ел, 6 октябрь, 718 нче карары 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков